ДҮШӘМБЕ
30 ДЕКАБРЬ
1940 ел.
№ 303 (6103)
Аерым номеры 10 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ, ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Партия-политик эш һәм хужалык мәсьәләләре

Бөек Ватаныбызда гаять зур иҗади эш бара. Советлар Союзының күп милләтле халыклары партиябезнең XVIII нче съезды тарафыннан куелган тарихи бурычларны—халык хуҗалыгы үсешенең өченче бишьеллык планын уңышлы үтәү өчен героик көрәш алып баралар. Массаның политик һәм производство активлыгы туктаусыз үсә. Социалистик төзелеш фронтында яңадан-яңа җиңүләр яулап алына. Болар барсы да урыннарда партия-оештыру эшенең һәм партия-политик эшнең көчәюе, партия оешмаларының җитәкчелек рольләре күтәрелә баруның нәтиҗәсе булып торалар.

Даһи юлбашчыбыз иптәш Сталин безне аерым уңышлар белән масаймаска, үзеңнең кимчелекләреңне һәм алдагы эшнең кыенлыкларын күрә белергә өйрәтә. «Хуҗалык уңышлары үзләре, аларның ныклыгы һәм озакка баруы,—ди иптәш Сталин,—бөтенләе һәм тулысы белән партия-оештыру һәм партия-политик эштәге уңышларга бәйләнгәнлеген, бу шарттан тыш хуҗалык уңышларының комга корылган булып калуы мөмкин икәнлеген төшендереп торырга». Димәк, хуҗалык уңышлары дәвамлы һәм ныклы булсыннар өчен партия-политик эшне тагын да көчәйтү, хуҗалык бурычларын политик эшләр белән нык бәйләп алып бару таләп ителә.

Аерым завод-фабрикалар, колхозлар һәм совхозлар янындагы башлангыч партоешмалар тәҗрибәсеннән чыгып шуны әйтергә кирәк: кайда партия-политик эш яхшы куелса, партия оешмалары социалистик ярышка һәм стахановчылык хәрәкәтенә конкрет җитәкчелекне тәэмин итсәләр, эш шунда яхшы бара, хуҗалык бурычлары уңышлы үтәләләр. Андый урыннарда штурмчылык кебек зарарлы методларга юл куелмый, производство планнары айдан-айга арттырылып үтәлә. Ә инде партия-политик эшкә, хуҗалык бурычларын политик эш белән дөрес бәйләп алып баруга җидди әһәмият бирелмәгән предприятиеләрдә һәм колхозларда моның киресенчә, эш алга бармый, бер урында таптанып тору килеп чыга.

Партия-политик эшкә, хуҗалык бурычларын политик эш белән дөрес бәйләп алып баруга әһәмият бирмәүнең нинди нәтиҗәләргә алып килүен күрсәтү өчен Казан шәһәрендәге аерым предприятиеләр мисаленнән шушындый бер факт китереп үтәргә мөмкин. Вахитов исемендәге жиркомбинат үткән елларны үзенең яхшы эшләве белән күпләргә үрнәк булып тора иде. Ә менә быел комбинат начар эшли, айдан- айга дәүләт планын үтәмичә килә. Сәбәп нәрсәдә соң? Төп сәбәп шунда: комбинат җитәкчеләре һәм партия оешмасы (секретаре иптәш Макутин) аерым уңышлар белән тынычланып калдылар, уңышларны дәвамлы һәм ныклы итү өчен практик чаралар күрмәделәр, партия-политик эш һәм оештыру эшләре, социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтенә җитәкче- [illegible]

[illegible] ганнар. Администрация эшен контроль ясау хокукыннан тулы файдаланмау, партия-политик эшне хуҗалык бурычлары белән нык бәйләп алып бармау әнә шуңа—производство планнарын өзелүенә, дәүләт заданиеләренең үтәлмәвенә китерә.

Партия оешмасының эше җыелышлар, утырышлар саныннан һәм анда кабул ителгән карарларның күләменнән чыгып түгел, бәлки партия һәм хөкүмәт директиваларын тормышка ашырудан, дәүләт заданиеләрен үтәүне тәэмин итүдән чыгып үлчәнә. Аның башкача булуы да мөмкин түгел. Чөнки партия-политик эш форма өчен түгел, максатка ирешү өчен алып барыла. Ә инде дәүләт белән идарә итүче безнең партиябезнең максаты һәркем өчен ачык билгеле. Ул — коммунистик җәмгыятьне төзеп җиткерү. Партия-политик эш һәм оештыру эшләре әнә шул бурычларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән булырга, социалистик төзелеш фронтында яңа җиңүләрне тәэмин итәргә тиеш.

Үзләренең эшләрен бүгенге таләпләргә туры китереп яңа баштан корган, партия-политик эшне хуҗалык бурычлары белән оста рәвештә бергә бәйләп алып баручы партоешмалар Татарстан предприятиеләрендә һәм колхозларында аз түгел, әлбәттә. Мехкомбинат, киез итек-фетр фабрикасы, кетгут заводы, 1 нче тегү фабрикасы, Беренче Май районының Чапаев исемендәге колхозы, Аксубай районының «Үсәр» колхозы янындагы партоешмалар кебек производство мәсьәләләре белән якыннан шөгыльләнүче оешмаларны шактый күп санарга мөмкин. Мондый партоешмалар коммунистлар массасы алдында, партиясез эшчеләр һәм колхозчылар массасы алдында зур авторитет һәм ихтирам белән файдаланалар. Чапаев исемендәге колхоз (Беренче Май районы) партоешмасы турында 60 яшьлек колхозчы Николай Яковлевич Митяшкин менә нәрсә ди:

— Колхозыбызны алдынгылар сафына чыгару өчен партия оешмасы күп көч куйды. Моның өчен без аңа зур бурычлы.

Партиясез картның чын йөрәктән әйтелгән бу гади сүзләре бик күп нәрсә турында сөйли. Берничә ел рәттән артта калып килгән Чапаев исемендәге колхоз быел район күләмендә алдынгылыкны яулап алды. Артель хуҗалыгы үсте, ныгыды. Колхоз үзеннән арткан 5.280 пот ашлыгын дәүләткә сатып, төрле инвентарьлар алды. Партоешманың нәрсә өчен көрәшүен колхозчылар күрделәр һәм аның күрсәтмәләрен намус белән үтәделәр. Коллектив хезмәт, бердәм көрәш җинде. Аны оештыручы һәм җитәкчелек итүче партоешма булды. Аерым партоешмалар эшеннән мондый мисальләрне бик күп китерергә мөмкин.

Сталинчыл өченче бишьеллыкның өченче елы социалистик Ватаныбызга сокланырлык уңышлар китерде. Партия оешмаларының бурычлары—бу уңышларны беркетеп калудан, аларны дәвамлы итү өчен көрәшүдән һәм, ниһаять, яңа елның яңа бурычларын уңышлы үтәү көрәшенә киң массаны туплаудан гыйбарәт. Предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, колхозларда, совхозларда [illegible]

Эстония халкының турылыклы кызы

ТАЛЛИН, 28 декабрь. (ТАСС). Таллин шәһәренең 11 һәм 12 нче сайлау участокларының сайлаучылары СССР Верховный Советына Милләтләр Советына үзләренең депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгән иптәш Юлиана Тельман белән очраштылар.

[illegible]

Эстония ССР да сайлау кампаниясе. Рәсемдә: „Коммунар" туку фабрикасының (Таллин шәһәре) яшь сайлаучылары җыелышында урта мәктәп укучысы, комсомолец Гейно Николь чыгыш ясый. Н. Янов фотосы (ТАСС).

Партиябезнең XVIII нче Бөтенсоюз конференциясе хөрмәтенә

БОНДЮГЛЫЛАР ҖАВАБЫ

(Үз хәбәрчебездән телефон буенча)

Партиябезнең XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясен чакыру турында ВКП(б) Үзәк Комитеты белдерүе Бондюг заводы эшчеләре, инженер-техник работниклары арасында зур политик һәм производство күтәренкелеге тудырды.

Заһид иптәш Җафаров начальник булган цех коллективы конференция хөрмәтенә булган социалистик ярышны заводта башлап җибәрүче булды. Цех коллективы январь һәм февраль айлары планын вактыннан элек үтәү һәм ягулыкка 10 процент экономия ясау йөкләмәсен алып, заводның башка цехларын ярышка чакырды.

Начальнигы Хаят иптәш Төхфәтуллина булган цех һәм 15 нче номерлы цех коллективлары бу чакыруны зур күтәренкелек белән каршыладылар һәм ике айлык планны конференция ачылу көне—15 нче февральгә үтәүне, барлык төр продукция эшләп чыгару бәясен 10 процентка киметүне ышандырдылар.

Завод коллективы ярышта алган йөкләмәсен эш белән ныгыта. Мәсәлән, иптәш Җафаров цехында эшләүче Бикмөхәмәтов, Устюгов һәм Шакиров кебек дистәләрчә иптәшләр көнлек норманы 120 процентка үтәп, ярышның алдынгы сафында баралар.

К. Әхмеров.

КОНФЕРЕНЦИЯ ИСЕМЕНӘ ПАРОВОЗ КОЛОННАЛАРЫ

ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе хөрмәтенә социалистик ярыш оештыру турында Әгерҗе депосының алдынгы машинистлары Казан тимер юлчыларына мөраҗәгать ясадылар. Бу чакыруга Казан тимер юлы эшчеләре һәм инженер-техник работниклары зур теләк белән кушылалар һәм үз өсләренә конкрет йөкләмәләр алалар.

Ярышның беренче нәтиҗәләре дә бар инде. Муром станциясе коллективы йөк төяү планын соңгы вакытларда системалы рәвештә арттырып үти башлады. Иҗади хезмәт активлыгының бу күтәренкелеге йөк төяү буенча декабрь ае планын срогынача үтәүне тәэмин итте. Юдино бүлеге работниклары да йөкләр ташу буенча еллык планны арттырып үтәүгә ирештеләр.

Паровозчылар аеруча яхшы эшлиләр. Муром депосы машинистлары Гусев, Солдатов, агалы-энеле Арсеновлар, Разумов, Зимин, Тресков һәм башка иптәшләр үз паровозларында техник тизлелек нормаларын әледән-әле арттырып үтәү белән бергә, таш күмергә дә күп кенә экономия ясыйлар. Сергач депосы машинисты иптәш Горланов техник тизлелек нормасын 10 километрга, иптәш Овчинников 6—7 километрга арттырып үтиләр. Шул ук депода котельщик булып эшләүче иптәш Гусев көнлек норма үтәлешен 600 процентка, юллар хуҗалыгының 4 нче дистанция тимерчесе иптәш Чалкин 400 процентка китмиләр.

Яңавыл һәм Красноуфим деполарында да ярыш үзенең гүзәл нәтиҗәләрен бирә. Монда алдынгы машинистлар тәкъдиме белән ВКП(б) ның XVIII нче Бөтенсоюз Конференциясе исеменә махсус паровоз колонналары оештырылды. Бу колонналарга кергән паровоз бригадалары үз паровозларын кышкы шартларда эшләтүнең сокландыргыч үрнәкләрен күрсәтәләр. Яңавыл депосы машинистлары конференция ачылу көненә ягулыкка иң кимендә 12 процент экономия ясау һәм 500 авыр йөкле поездлар йөртү белән каршылау өчен намус белән көрәшәләр.

Г. Шәрәфеттинов.

ТӨЗҮЧЕЛӘР ҖАВАБЫ

14 нче төзү тресты эшчеләре һәм инженер-техник работниклары коллективы тарихи конференция хөрмәтенә производство бүләкләре хәзерли.

6 нчы контора коллективы социалистик ярышка кушылып, конференция ачылу көненә 2 шәр катлы 5 агач йорт һәм 3 таш йорт төзелешен срогынача тәгәлләү йөкләмәсен алды. 7 нче контора эшчеләре дә шундый ук йөкләмәләр алып, ярышта җиңеп чыгу өчен көрәшәләр.

Зиа Гәрәй.

ПЛАН СРОГЫННАН ЭЛЕК ҮТӘЛДЕ

„Кызыл мехчы" кустарь-һөнәрчелек артеле (Балтач районы) еллык планны срогыннан элек—25 нче декабрьдә—үтәде. 2 миллион 565 мең сумлык продукция эшләп чыгарылды.

Артель стахановчыларыннан Г. Сафина норманы системалы рәвештә 280 процентка, Р. Камалова 256 процентка, Ф. Фатыйхова 207 процентка үтиләр.

Артель 1940 нчы елның ахрына кадәр, планнан тыш, 80 мең сумлык продукция эшләп чыгарачак.

(ТатТАСС).

МОЛОТОВ РАЙСОВЕТЫНЫҢ VI НЧЫ СЕССИЯСЕ

Бүген, Авыл Хуҗалыгы Институты бинасында (Карл Маркс урамы, 65 нче йорт), 19 сәгатьтә, хезмәт ияләре депутатларының Молотов район Советының чираттагы VI нчы сессиясе була.

Молотов райсоветы башкарма комитеты.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕКНЕ БАРЛЫК ТАРМАКЛАР БУЕНЧА ҖӘЕЛДЕРЕРГӘ

АЛДЫНГЫ КОЛХОЗДА

ВКП(б) Өлкә Комитетының III нче пленумы карарларын өйрәнгәннән соң Кызыл Йолдыз районының „Авангард" колхозында (Владимиров авылы) язгы чәчүгә хәзерлек яхшырды. Чәчү орлыкларын тазартуда, басуга тирес чыгаруда, кар тотуда һәм җирле ашламалар хәзерләүдә катнашучылар арасында социалистик ярыш договорлары төзү һәм ярышның үтәлешен системалы рәвештә тикшереп бару эшнең уңышлы баруына зур этәргеч булды.

Колхозда чәчү орлыклары тулысынча тупланган һәм яхшылап тазартылып куелган. Орлыкларның саклануы даими рәвештә тикшерелеп барыла. Сабаннарга, чәчү машиналарына һәм арбаларга ремонт ясау тәгәлләнгән. Тимерче иптәш Беловның үз эшенә аеруча җидди игътибар бирүен, машиналарны тизрәк тә һәм яхшырак итеп тә төзәтү өчен бөтен көчен биреп тырышып эшләвен әйтергә кирәк.

Кышкы агрономия чаралары планнарын үтәү һәм арттырып үтәү өчен көрәш көннән-көн кыза бара. Кар тоту планы 55 процентка, басуга тирес чыгару планы 55 процентка, көл җыю 40 процентка үтәлгән.

Агротехника түгәрәгендә эш тәртипле бара. Аның 6 занятиесе булды инде. Түгәрәккә 60 кеше йөри.

„Авангард" колхозы членнары кышкы агрономия чаралары планнарын яхшы сыйфатлы итеп арттырып үтәү өчен „Тимер Юл" колхозы членнарын социалистик ярышка чакырдылар.

М. Гыйлаҗев.

ЭШНЕ ЧИРАТКА КУЯЛАР

Язгы чәчүгә хәзерлекне барлык эш тармаклары буенча бергә бәйләп алып барасы урында Баулы районының „Кызыл Армеец" колхозында күп эшләрне чиратка куялар. Мисаль өчен колхозның 3 нче бригадасын (бригадиры иптәш Миназов) алырга була. Бу бригада авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау һәм орлык хәзерләү эшләрен күптән тәгәлләгән иде. Ә менә кар тоту чараларын үткәрүне бары 36 процентка гына үтәгән. Басуга тирес чыгару, көл һәм башка җирле ашламалар хәзерләү эшенә яңа гына керешкән.

Икенче бригадада да (бригадиры иптәш Зиннәтев) шундый ук хәл.

Колхозның барлык бригадаларында эш шартлары бер төрле булуга да карамастан, 3 нче бригада (бригадиры иптәш Ситдиков) бигрәк тә артта бара. Бу бригадада чәчкечләрдән башка бер генә машинага да кул тидерелмәгән әле.

Колхоз правлениесе бригадаларда язгы чәчүгә хәзерлекнең барышы белән җитәрлек кызыксынмый, бригадирлардан эш таләп итми, артта калучыларга карата килешүчәнлек күрсәтә.

А. Вагыйзов.

Яңа Чишмә һәм Минзәлә сайлау округларында сайлау кампаниясе

ПРОИЗВОДСТВО АКТИВЛЫГЫ ҮСӘ

Әгерҗе районы хезмәт ияләре 470 нче номерлы Минзәлә сайлау округыннан Милләтләр Советына депутат сайлау кампаниясе уңае белән производствода яңа җиңүләр яулап алу өчен көрәшәләр. Колхозларда, МТС ларда һәм транспортта эшләүчеләр яңа йөкләмәләр алалар. Районның Тирсә МТС ы коллективы тракторларга ремонт ясауны яхшы сыйфатлы итеп срогыннан алда үтәү өчен көрәшә. Сайлаулар көненә тракторларның 55—60 процентына, ә тагылма инвентарьларның барлык 100 процентына ремонт ясауны йөкләмә итеп алдылар. Тракторчыларның иптәш Нәфиков бригадасы сайлау көненә 2 тракторны ремонтларга йөкләмә алды һәм үзе белән ярышка башка бригадирларны да чакырды.

Әгерҗе узелы тимер юлчылары арасында да социалистик ярыш көннән-көн киң җәелә. Станциянең паровоз депосы слесарьлары паровозларның ремонтка кермичә күбрәк эшләүләрен тәэмин итү өчен паровоз бригадалары арасында социалистик ярыш договорлары төзеделәр. 215—33 нче номерлы паровоз слесаре Евдокимов һәм машинист Шкатов иптәшләр ремонтның сыйфатын тагын да яхшырту, паровозны чиста итеп тоту йөкләмәсен алдылар.

Станциянең диспетчерлар коллективы соңгы вакытта үзенең эшен сизелерлек рәвештә яхшыртты. Яңавыл участкысы диспетчеры иптәш Федотовның паровоз һәм поезд бригадалары арасында социалистик ярышны киң җәелдерүе нәтиҗәсендә, поездларның коммерческий йөрешләре билгеләнгәнгә караганда арттырылып үтәлә башлады.

Сайлауларга хәзерлек уңае белән, узелның барлык участкыларында да социалистик ярыш договорларының үтәлеше тикшерелә һәм договорлар яңартып төзеләләр.

К. Халиков.

САЙЛАУ ЗАКОНЫН ӨЙРӘНӘЛӘР

Хезмәт ияләре депутатларының Әгерҗе район советы башкарма комитеты 31 сайлау участкысы төзеп, участкы күләмендәге сайлау комиссияләренең составын игълан итте. Участкы комиссияләре составына 352 кеше сайланды. Аларның 87 се хатын-кызлар.

Районның колхозларында һәм предприятиеләрендә агитаторлар масса-аңлату эшләрен җәелдерделәр. Сталин Конституциясен һәм „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение"не өйрәнү буенча 208 түгәрәк оештырылды. Бу түгәрәкләргә сайлаучылардан 2 меңнән артык кеше йөри. Конституцияне һәм сайлаулар турындагы законны өйрәнү Биектау авыл советында (башкарма комитеты председателе иптәш Нуриев) аеруча яхшы оештырылган. Биредә 17 түгәрәк эшли. Аларга 350 кеше тартылган.

Агитаторлар киңәшмәләре

ОКТЯБРЬ НОРЛАТЫ, 28 декабрь. 26 нчы декабрьдә районның 6 урынында агитаторларның, стена газеталары редакторларының, уку өйләре һәм колхоз клублары мөдирләренең куст киңәшмәләре булып үтте. Бу киңәшмәләрдә сайлау кампаниясе турындагы мәсьәләләр тикшерелде. Куст киңәшмәләрендә бөтенесе 365 кеше катнашты. (ТатТАСС).

САЙЛАУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Хезмәт ияләре депутатларының Беренче Май район советы депутаты иптәш Газизуллин үзенең сайлаучылары белән әледән-әле очрашып тора. Киров исемендәге колхозда булган соңгы очрашу җыелышында 205 кеше катнашты. Иптәш Газизуллин райсоветның 5 нче сессиясендә каралган мәсьәләләр белән таныштырды. Депутат, шулай ук, хуҗалык өлкәсендә колхозның зур уңышларга ирешкәнлеген, кооперациягә 9 мең пот ашлык сату шикелле уңышлы якларны күрсәтеп үтте.

Иптәш Газизуллин колхозга автомашина алуда, мәктәпнең финанс белән тәэмин ителүенә булышуда, авылда артизиан коелары булдыру чараларын күрүдә булган эшләрен күрсәтеп үтте.

Депутат, шулай ук, аерым колхозчыларга, кызыл армеецларнең семьяларына киңәшләр, ярдәмнәр бирелгәнлекне әйтеп үтте.

Һ. Галиев.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

КАЗАН—БӨГЕЛМӘ ТИМЕР ЮЛЫ ТӨЗЕЛЕШЕ ПАРТОЕШМАЛАРЫ ҮЗ КАРАРЛАРЫН ҮТӘМИЛӘР

Кышкы салкын көннәрдә дә тиз һәм яхшы итеп төзергә! Большевиклар партиясе һәм Совет хөкүмәте төзүчеләр алдына әнә шундый сугышчан бурыч куйдылар. Орденлы Татарстан магистрален—Казан—Бөгелмә тимер юлын төзүчеләр алдында да шул ук бурыч тора. Төзү эшен кышкы көннәрдә дә уңышлы алып бару өчен, аңа, иң беренче чиратта, тулы һәм яхшы итеп хәзерләнергә кирәк.

Юл Эшләре Халык Комиссары иптәш Л. М. Каганович 13 нче ноябрьдә селектор аша үткәрелгән киңәшмәдә моңа аеруча тукталды. Ул, тимер юлны төзүчеләрдән эш күләмен кышкы көннәрдә тагын да арттыруны таләп итте.

Моның өчен практик эш башларга, кышкы эш планын үтәүгә хәзерлекне киң җәелдерергә кирәк иде. Казан—Бөгелмә тимер юлы төзелеше кышкы салкыннарны ничек каршылады соң? Турыдантуры әйтергә кирәк: бик начар каршылады. Дөрес, төзелеш управлениесе җитәкчеләре, иптәш Л. М. Каганович күрсәтмәләреннән чыгып, бик яхшы һәм бик конкрет чаралар да билгеләделәр. Участкылардагы партоешмалар бу мәсьәләне гомуми җыелышларда тикшереп, карарлар чыгардылар, коммунистларны аерым эш тармакларына беркеттеләр.

Моннан соң айдан артык вакыт үтте. Ләкин, бу карарларның күпчелеге тормышка ашырылмады. Аерым тармакларга беркетелгән кайбер коммунистлар үзләренә йөкләтелгән бурычны бик тиз оныттылар, ә партоешмалар һәм аларның секретарьлары Кузнецов һәм М. Хөсәенев иптәшләр карарларның үтәлешен үз вакытында тикшермәделәр. Моны раслау өчен конкрет фактларга тукталып үтик.

Менә икенче участкы. 22 нче ноябрьдә үткәрелгән партия җыелышы „Торак йортларның кышка хәзерлеген тикшерү өчен җәмагат бригадалары оештырырга" дигән карар кабул итә. Кыш озак көттермәде, үз вакытында килде. Ләкин торак йортларны кышка хәзерләмәгәннәр һәм аларның кышка хәзерлеген тикшерү өчен җәмагат бригадалары да оештырылмаган. Партошма секретаре иптәш М. Хөсәенев (участкы начальнигының политик эшләр буенча ярдәмчесе) бу мәсьәләдә тулы тынычлык күрсәтә.

— Җыелыш тарафыннан аерым тармакларга беркетелгән коммунистлар ни өчен эшләмиләр?— дип сорагач, ул, җыелыш карарын үтәмәүче коммунистларны якларга маташа.

— Потапов,—ди ул,—төрле җирләргә йөрүдән бушамый. Макаров, Сперанский канцеляриядә эшлиләр, аларга биредә дә эш җитәрлек (?!).

Беренче участкыдагы партоешманың гомуми җыелышында (18 нче ноябрьдә), иптәш Л. М. Каганович күрсәтмәләре нигезендә билгеләнгән чараларны тикшерү белән бергә, атлар паркының кышка хәзерлеге каралды. Төзелеш өчен бу—гаять әһәмиятле мәсьәлә.

Беренче участкыда барлыгы 72 ат бар. Ләкин алар тулы файдаланылмыйлар. Чөнки сбруй җитми. 72 атка бары тик 20 комплект сбруй бар. Бу—дүрт атка бары бер камыт дигән сүз. Шуның аркасында 52 ат һәр көнне ял итә. Паркта 40 чана һәм шул ук санда дип әйтерлек дуга җитешми.

Партия җыелышы аларның һәммәсен дә искә алып, бик яхшы карар кабул итте. Җыелыш, 25 нче ноябрьдә дә соңга калмыйча конюшняне төзеп бетерергә, салам кисә торган 2 машина булдырырга, атларны карау һәм алардан файдалану турында киңәшмә үткәрергә, тулы комплект сбруй булдырырга тәкъдим итте. Парк буенча кабул ителгән карарны тормышка ашыруны коммунист иптәш Вавиловка (атлар паркының мөдире) йөкләде.

Партоешма секретаре иптәш Кузнецов иптәш Вавиловтан карарны үтәүне таләп итәргә һәм аңа кирәк ярдәмне күрсәтергә тиеш иде. Ләкин, ул моны вактында эшләмәде һәм нәтиҗәдә карар шул карар килеш протоколда гына калды, тормышка ашырылмады. Хәзер дә әле участкыдагы атлар өчен тиешле күләмдә камытлар, дугалар булдырылмаган.

Җыелыш карары—ул, оешманың практик эш программасы. Партоешма секретарьлары М. Хөсәенев һәм Кузнецов иптәшләргә моны күптән аңларга вакыт инде. Карар чыгаргач аны үз вактында үтәргә һәм дөрес үтәлүен тикшерергә кирәк.

Рим Баһау.

Кандидатлар белән эшләүгә җавапсыз карыйлар

Норлат районының „Игенче" колхозы янындагы партоешма секретаре иптәш Афзалов кандидатлар арасында планлы эш алып бармый, аларга булышлык күрсәтми. А. Әхметов һәм М. Зиаттинов иптәшләр 1938 нче елның август һәм октябрь айларыннан бирле кандидат булып йөриләр. „Кызыл Урманчы", „Алга", Ленин исемендәге колхозлар һәм Тат. Танай урта мәктәбе янындагы башлангыч партоешмаларда да кандидатлар белән эшләү начар куелган. Районда стажлары үткән 78 кандидат исәпләнә.

Кандидатлык стажы ВКП(б) га член булып керергә теләүчеләр өчен зур сынау чоры. Бу вакыт эчендә һәрбер кандидат практик эштә сыналырга һәм член булып керү өчен ныклап хәзерләнергә тиеш.

Афзал Җәләл.

Комсомол оешмасы һәм колхоз

„Беренче Май" колхозы янындагы комсомол оешмасы колхоз правлениесенә зур ярдәм итә. Оешма үзенең чираттагы җыелышында язгы чәчүгә хәзерлек турында колхоз председателенең информациясен тыңлады һәм язгы чәчүгә тулы хәзерлекне тәэмин итү буенча эшлекле тәкъдимнәр ясады.

Колхозда ике урында агротехника түгәрәге оештырылды. Бу түгәрәкләргә 55 тән артык кеше йөри, аларга колхоз агротехнигы комсомолка Садыйкова җитәкчелек итә. Зоотехника түгәрәге оештырылып, аңа терлекчелек эшендә эшләүче барлык колхозчылар тартылды. Хәзер колхозда орлыкларны чистарту эше тәмамланып килә.

Оешма секретаре Магсумов авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлауда яхшы эш үрнәкләре күрсәтте. Ул колхозның алдынгы тимерчесе. Иптәш Магсумов чәчү машиналарын һәм сабаннарны яхшы сыйфатлы итеп ремонтлады. Ул кичләрен колхоз яшьләре арасында клубта була, яшьләр белән берлектә клубтагы түгәрәкләрнең эшләренә ярдәм итә.

Комсомол җыелышлары вактында үткәрелә. Оешма союздан тыш яшьләр арасында зур эш алып бара. Колхозның алдынгы яшьләреннән комсомол сафына 6 кеше кабул ителде. Хәзер оешмада 25 комсомолец бар. Алар „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н зур дәрт белән өйрәнәләр.

Ш. Шамаров,
ВЛКСМ ның Теләче райкомы секретаре.

Администрация эшенә контрольне көчәйтергә

Кызыл Йолдыз районындагы МТС партоешмасы партия-политик эшне хуҗалык мәсьәләләре белән нык бәйләп алып барырга, администрация эшенә контрольлек итү хокукыннан тулы файдаланырга тиеш иде. Ләкин партоешма (секретаре иптәш Галәмиев) бу эш белән бөтенләй дип әйтерлек шөгыльләнми.

Партоешма отчет-сайлаулардан соң (10 ай вакыт эчендә) бары 9 тапкыр гына коммунистларның гомуми җыелышларын үткәргән. МТС эше турында партоешмада 4 мәсьәлә каралган. Бу мәсьәләләр буенча чыгарылган карарлар үтәлмәгәннәр, МТС эшендә бер төрле дә борылыш тәэмин ителмәгән. Ул еллык производство планын 68 процентка гына үтәгән. МТС язгы чәчүгә дә начар хәзерләнә. 74 тракторның бише генә ремонтланган, сабаннарның 25 проценты, чәчкечләрнең 18 проценты, культиваторларның 52 проценты гына ремонтланган. МТС тагы 7 автомашинаның берсенә дә әле ремонт башланмаган, комбайннарны ремонтлау эшенә дә керешелмәгән.

Партоешма МТС тагы бу җитди кимчелекләрне бетерү өчен көрәшкә коллективны тупламаган. МТС тагы кайбер эшчеләр тарафыннан хезмәт дисциплинасының тупас рәвештә бозылуы моны ачык күрсәтә. Прогулчы Афанасьев, Гаврилов һәм Вәлиевaларга карата МТС дирекциясе тарафыннан бер төрле дә чара күрелмәгән.

Директор иптәш Гәрәев прогул ясаучылар турындагы материалларны атналар-айлар буе тикшерү-суд органнарына җибәрмичә яткыра. Прогулчы Хәлимев турындагы материал 28 көннән соң, Әхмәтҗанов, Фатыйховлар турындагы материаллар 11 көннән соң гына тикшерү-суд органнарына бирелгән. Ә коммунист Гәрәевкә карата партоешманың бер төрле дә чара күргәне юк.

М. Гыйлаҗев,
ВКП(б) ның Кызыл Йолдыз райкомы инструкторы.

Үз бурычын үтәмәүче бер парткабинет турында

Марксизм-ленинизм фәнен өйрәнүче партияле һәм партиясез большевикларга парткабинетлар зур булышлык күрсәтергә тиешләр. Үзенең теоретик белемен күтәрү өстендә эшләүче һәрбер иптәш үзен кызыксындырган һәм төшенүе авыр булган мәсьәләләр турында парткабинеттан ачык һәм тулы җавап ала алырга тиеш. Ләкин кайбер парткабинетлар үзләренә йөкләнгән бу җаваплы бурычларны тиешенчә үтәп җиткермиләр әле. Мисаль өчен ВКП(б) ның Минзәлә райкомы янындагы партия кабинетын алырга мөмкин.

Бу парткабинетның планы большевизмның теориясен үзләштерү өстендә эшләүче иптәшләрнең сорауларыннан чыгып төзелмәгән. Башлангыч партия оешмалары белән һәм партия тарихын үзлекләреннән өйрәнүче аерым иптәшләр белән элемтә урнаштырылмаган. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнүне тәмамлаган иптәшләрнең хәзер нәрсә белән шөгыльләнүләрен парткабинет белми, алар белән киңәшмәләр уздырылмый. Групповой консультацияләр очраклы рәвештә генә уздырылалар. Индивидуаль консультацияләр бөтенләй булганы юк.

Парткабинет мөдире иптәш Газизовның политик яктан хәзерлеге түбән һәм ул үзенең теоретик артталыгын бетерү өстендә эшләми. Шуның нәтиҗәсе буларак, иптәш Газизов катлаулы теоретик мәсьәләләрне чишүдә булышлык кирәк булган иптәшләргә практик ярдәм күрсәтә алмый.

Парткабинет мөдире марксизм-ленинизмны яхшы белергә, һәр яктан белемле һәм культуралы булырга, активка теоретик мәсьәләләрне чишүдә ярдәм күрсәтергә тиеш. Ләкин иптәш Газизов бу бурычларны үтәүдән ерак тора.

Актив.

БИЕКТАУ РАЙОНЫНДА ЮГАРЫ ИГЕН УҢЫШЫ ӨЧЕН КӨРӘШЧЕЛӘР

Элекке заманда: „Нәрсә чәчсәң, шуны урырсың", дигәннәр. Бу—бик дөрес әйтелгән сүз. Чүпле, начар орлык чәчелсә, аның белән уңышы да шундый ук чүпле була. Яхшы орлык чәчелсә, уңыш та шул кадәр әйбәт була. Яхшы сыйфатлы орлык иген уңышын күтәрүдә, һичшиксез, зур рол тота. Ләкин без, югары иген уңышы алуга ирешү өчен, яхшы орлык та чәчәргә, срогында да чәчәргә, орлыкка җитәрлек кулланда тулыклы азык та бирергә, туфракны да яхшылап хәзерләргә һәм урып-җыюны да һичбер югалтусыз уздырырга тиешбез. Кыскасы, һәрбер культурага карата агрономия чараларын тулысынча үткәрергә кирәк. Төп шарт әнә шундый.

Биектау районының „Красный Восток" колхозында 1939 нчы елда шулай эшләгәннәр. Кар тоту планын 100 процентка үтәгәннәр, басуга тирес чыгару буенча 3.200 йөкле планны 3.524 йөккә җиткереп үтәгәннәр. Әнда, башка төр агрономия чараларын да, шулай ук, тәгәл үтәргә тырышканнар, агрономия киңәшенә һәм вакытта ук колак салганнар. Нәтиҗәдә, бу колхоз 1940 нчы елда бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 14,81 центнер, арыштан һәр гектарыннан 20 центнер уңыш алды. „Пролетарий" колхозы да, барлык агрономия чараларын тулысынча һәм дөрес итеп үткәреп, бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 100,5 пот уңыш алды.

Ләкин Биектау районының күп кенә колхоз җитәкчеләре агрономия чараларын тулысынча үткәрүгә игътибар бирмиләр. Районда 1940 нчы ел көз көне туңга сөрү планының бары 52,2 проценты гына үтәлгән калуы моны ачык күрсәтә.

Бу район шәһәр тирәсе яшелчә зонасына керә. Шулай булгач, яшелчәчелеккә аеруча кайгыртучанлык белән карарга тиеш иде. Ләкин без хәлнең киресен күрәбез. Менә бер факт. 1940 нчы елда гына Молотов исемендәге колхозның яшелчә бригадасы бригадиры Мухин бөтенләй ярыксыз суган һәм кишер орлыкларын чәчеп, колхозга бик зур зиян китергән. Мондый фактлар башка колхозларда да булган.

Биектау районы җитәкчеләре 1940 нчы елгы әнә шундый күңелсез фактлардан тиешле нәтиҗә чыгарырга һәм аларны кабатламау өчен нык чаралар күрергә тиешләр иде. Ләкин, кызганычка каршы, биредә андый нәрсә күренми әле. Күптән түгел генә районда колхоз председательләренең, ревкомиссия председательләренең һәм колхоз хисапчыларының киңәшмәсе булды. Киңәшмә, районда 1941 нче елгы язгы чәчүгә хәзерлекнең барышы буенча да һәм шулай ук яшелчәчелек буенча да бик нык җитешсезлекләр барлыгын күрсәтте. Районның күпчелек колхозларында көзге-кышкы чорда эшләнергә тиешле эшләрне үтәүдә бик зур артта калу бар. Җирле ашламаларның булган, кар тоту буенча планы үтәлмәгән. Әле хәзерге көнгә кадәр районда тиешенчә 4 мен центнер көлнең бары 117 центнеры гына җыелган. Басуга тирес чыгару планы бары 5,3 процентка, кош тизәге хәзерләү планы бары 4 процентка үтәлгән. Районның күпчелек колхозларында бу эшләр бөтенләй алып барылмый.

Колхозларда хәзерлеге шулай ук һич тә канәгатьләнерлек түгел. Орлыкның күпчелеге тазартылмаган һәм тирерланмаган. Орлыкка калдырылган бодайны күләмле сортлар беленән, начар, кайбер колхозларда 20 дан артык сыйфатсыз орлык фактлары бар. Күп кенә колхозларда яшелчә орлыклары җитәрлек түгел. Ләкин колхоз председательләре да һәм шулай ук район бик шул, бу хәл тиешле, кирәкле әле орлык табу чарасын күрмиләр.

Ауыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау, телпилдаг тозу, парнилар хәзерләү бик акрын бара.

Кардлар хәзерләү буенча да хәлнең тревогалы икәнлеген күрергә кирәк. Дөрес, кайбер колхозларда („Кызыл Кул", „Урал" Тукай һәм Ворошилов исемендәге, барлыгы—14 колхозда) орлыкны ук, уңыш белән кукеседә тик берлә кирәкле, эшләр әле.

Партиянен Биектау район комитеты һәм район советы башкарма комитеты язгы чәчүгә хәзерлекне эшен хәзер тәэмин итү көченә бу тревогалы хәлдән нык нәтиҗә чыгарып, кискен чаралар күрергә тиешләр.

В. Судаков.

КАР ТОТУ

Мамадыш районындагы күп кенә колхозлар һәм совхозлар кар тотуга керештеләр. „Доброволец" совхозы кар тоту „Добролы" ... 60 гектар, Молотов исемендәге колхоз 50 гектар, „Доброволец" колхозы 40 гектар мәйданда кар тоту үткәрделәр инде. Кар тотуда агротехниканы өйрәнү түгәрәкләре членнары актив катнашалар.

Ләкин бу мөһим эшнең кайбер колхозларда әлегә кадәр башланганы юк. „Агробаза" совхозы бу эшне, җиргә яткан карны сөрү һәм казу юлы белән үткәрә, ягни агротехника кагыйдәләрен тупас рәвештә боза. (ТатТАСС).

ХАЛИКОВ БРИГАДАСЫ АЛДА БАРА

КАЙБЫЧ, 29 декабрь. (ТатТАСС). Мөрәле МТС ының тракторчылары һәм эшчеләре арасында социалистик ярыш киң җәелде. МТС коллективы ремонтның яхшы сыйфатлы булуы һәм хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен көрәшә. Иптәш Халиков җитәкчелегендәге өченче бригада тракторларга һәм тагылма инвентарьга ремонт ясауны тулысынча тәмамлады.

МТС ның барлык хезмәткәрләре дә агротехника укуларына тартылган.

ЛЕНИН—СТАЛИН ПАРТИЯСЕ САФЛАРЫНЫҢ ЧИСТАЛЫГЫН САКЛАРГА

К. П. ЖУКОВ

ВКП(б) Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире.

ВКП(б) сафларына яңа членнар кабул итү—җитди һәм җаваплы эш. Партиябезнең юлбашчылары—Ленин һәм Сталин—партия членнарына, аның составына һәр вакыт зур игтибар бирделәр, большевиклар партиясе сафларының чисталыгын саклау турында көн саен кайгыртучанлык күрсәтергә өйрәттеләр һәм өйрәтәләр.

Большевиклар партиясе, эшчеләр сыйныфының алдынгы отряды буларак, үзенең сафларына бары тик аңлы, актив, коммунизм эшенә ахрынача бирелгән эшчеләрне, крестьяннәрне һәм интеллигентларны кабул итә. Партиябезнең ишекләре ВКП(б) члены булырга лаеклы кешеләр өчен генә ачык. Партиягә яңа членнар ВКП(б) уставы нигезендә, бары тик индивидуаль тәртиптә генә кабул ителәләр.

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе хезмәт ияләре арасында зур авторитет һәм ихтирам белән файдалана. Партия сафларының алдынгы эшчеләр, колхозчы крестьяннар һәм интеллигентлар хисабына үсүе моны ачык күрсәтә. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң Татарстан партоешмасында ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 14.500 дән артык һәм ВКП(б) члены итеп 8 меңгә якын кеше кабул ителде.

ВКП(б) га яңа членнар кабул итү эшендә җитди кимчелекләр дә бар әле. Төп кимчелек итеп, күп кенә партоешмаларда партиягә кабул итүдә сан артыннан куунның дәвам итүен күрсәтергә кирәк. ВКП(б) ның Баулы райкомы пленумы шушы елның 25 нче октябрендә чыгарган карарында кайбер башлангыч партоешмаларны, аларда кандидатлар аз кабул ителгән, дип гаепләгән. Совхоз партоешмасында соңгы ярты ел эчендә партия сафына 3 кандидат кабул ителгән булса да, пленум бу оешмада партиягә кабул итү эшләре алып барылмый дип күрсәткән. Шулардан чыгып Баулы райкомы башлангыч партоешма секретарьларына ВКП(б) га яңа членнар кабул итүдә җитезрәк эшләргә тәкъдим иткән һәм, хәтта, партиягә кабул итү буенча кергән гаризаларны карау буенча сроклар да билгеләгән. Райком күрсәтмәсендә гаризалар башлангыч оешмаларда 3 көндә, ә райком бюросында 5 көндә каралырга тиеш диелә. ВКП(б) ның Кызыл Армия райкомы да гаризаларны карау өчен сроклар билгеләгән (1 нче ноябрь карары). ВКП(б) Өлкә Комитеты Баулы һәм Кызыл Армия райкомнарының бу карарларын юкка чыгарды. Өлкә Комитеты бу райкомнарга, алар ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын аңламаганнар һәм башлангыч оешмаларга партиягә кабул итү буенча сан артыннан куугa этәрә торган ялгыш күрсәтмә биргәннәр, дип аңлатты.

Азнакай районы җир бүлеге янындагы башлангыч партоешма, шушы елның 3 нче сентябрендә булган җыелышта, партиягә кабул ителергә тиешле кешеләр резервын булдырырга дип карар кабул иткән һәм, хәтта, партиягә керер өчен хәзерләргә дип, аерым кешеләргә коммунистларны беркеткән. Заготзерноның Вандовка бүлеге (Мамадыш районы) янындагы башлангыч партоешма, һәрбер коммунист партиягә берәр кеше вербовать итәргә тиеш, дип карар чыгарган.

Партия сафларын сан ягыннан үстерү артыннан куу—партиягә яңа членнар кабул иткәндә индивидуаль сайлап алуның Ленинчел—Сталинчыл принципын бозуга, партиягә керүчеләр алдына куела торган таләпләрне киметүгә, ВКП(б) уставының „Партия членлыгына аңлы, актив һәм коммунизм эшенә чын күңелдән бирелгән эшчеләр, крестьяннар һәм интеллигентлар кабул ителә" дигән таләпләреннән чигенүгә алып бара. Сан ягына ориентировка тоту—партиягә кабул итүгә өстән карауга, нык булмаган һәм лаеклы булмаган элементлар белән партия сафларының чүпләнүе куркынычына китерә.

Партиянең Яңа Чишмә райкомы 1940 нчы елның июнендә ВКП(б) членлыгына кандидат итеп Михаил Балкинны кабул итә. Озак та үтми, ноябрь аенда, хулиганлыгы өчен, партиянең һәм Совет властеның дәрәҗәсен төшерүе өчен райком аны партиядән чыгарырга мәҗбүр була. ВКП(б) ның Киров райкомы шушы елның июль аенда Сәлимевне кандидат итеп кабул итә. Сәлимев хулиганлыгы һәм башка эшләре өчен ноябрь ае башларында партиядән чыгарыла һәм судка бирелә. СССР Верховный Советы Президиумының 26 нчы июнь Указыннан соң үткән вакыт эчендә генә дә партиянең Татарстан оешмасы буенча 1940 нчы елны партиягә кабул ителүчеләрдән 40 ка якын кеше, дәүләт һәм партия дисциплинасын бозулары, прогул ясаулары өчен, партиядән чыгарылды.

Бу фактлар күп кенә партоешмаларда ВКП(б) сафларына керергә теләүчеләрнең гаризаларын тикшерүдә җиңел караш урын алуы турында сөйлиләр. Партиягә кабул итү турындагы гаризаны караганда, башлангыч партоешма җыелышы гариза бирүчене партиягә кабул итәргәме, яки юкмы икәнлекне хәл итәргә тиеш. Партия оешмасы ВКП(б) сафына яңа членнар кабул итү эшенә тулы җаваплылык белән якын килгәндә генә, һәрбер гаризаны тиешенчә тикшергәндә генә бу җитди мәсьәлә дөрес хәл ителә ала. Партиянең һәрбер члены Ленинның „Партиянең һәрбер члены партия өчен җаваплы һәм партия һәрбер члены өчен җаваплы" дигән күрсәтмәләрен бер генә минутка да онытмаска тиеш.

Күп кенә башлангыч партоешмалар ВКП(б) сафларына яңа членнар кабул итү турындагы эшләрне караганда, партиягә керергә теләүчегә бер-ике сорау бирү белән чикләнәләр, кайбер вакытларда бөтенләй сорау да бирмиләр. Мәсәлән, Ленин исемендәге завод парткомы утырышында С. ның гаризасын караганда „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н ничек өйрәнәсез" дип, бер генә сорау биргәннәр. Г. гаризасын караганда да ике сорау бирү белән чикләнгәннәр. Киров исемендәге завод партоешмасында кабул ителгән 5 кешегә сораулар бөтенләй бирелмәгән, алар, оешма секретаре информациясе буенча гына кабул ителгәннәр.

ВКП(б) га яңа членнар кабул итү эшендә булган кимчелекләр, бу эшкә кайбер райкомнарның әһәмият биреп җиткермәүләреннән дә килеп чыга. Алар партоешмаларның сан ягыннан үсеш мәсьәләсендәге дөрес булмаган практикаларын читләтеп үтәләр. Дөрес булмаган карарларны юкка чыгарганда, күп кенә хәлләрдә, аның мотивларын аңлатмыйлар, партоешмаларны үзләренең ялгышлары мисалендә өйрәтмиләр. 1940 нчы елда ВКП(б) ның Сталин һәм Киров райкомнары юкка чыгарылган карарларның (партиягә кабул итүләр буенча) 15—20 процентын гына башлангыч партоешмаларның җыелышларында аңлатканнар. Райкомнар партиягә кабул итүне кире кагу турындагы мотивларны аңлатуны, күп кенә хәлләрдә, башлангыч партоешма секретарьларына тапшыралар, ә инде алар, райком фәлән кешене партиягә кабул итмәде, дип белдерү белән генә чикләнәләр, аның сәбәпләрен әйтмиләр.

Оешманың сан ягыннан үсеше белән мавыгучылар, партия составында агылышның күбәюен сизмиләр. Киров районы партоешмасында октябрь—ноябрь айларында партиягә 15 кеше кабул ителгән, ә шул ук чорда партиядән 18 кеше чыгарылган. Шушы ук вакыт эчендә Сталин районы партоешмасында 24 кеше кабул ителгән, ә 29 кеше чыгарылган. Казан шәһәре партоешмасында 92 кеше кабул ителгән, 80 кеше чыгарылган.

Коммунистның үсүе, тәрбияләнүе, организацион чыныгулар алуы практик эшкә бәйләнгән. Партиянең һәм хөкүмәтнең карарларын үтәү буенча конкрет эш алып бару коммунистны чыныктыра. Марксизм-ленинизм тәглиматын яхшы итеп пропагандалау коммунистның кругозорын киңәйтә, хәрәкәт итү өчен ана кулланма бирә. Райкомнарның пленумнарында партиягә яңа членнар кабул итү турында райком бюроларының отчетлары тыңланды. Бу, партиягә кабул итү мәсьәләләренә җиддиерәк һәм игътибар белән карауны тәэмин итү буенча яхшы нәтиҗәләр бирде. Шуның белән бергә, бу пленумнарда райком бюролары отчетлары буенча чыгарылган карарларда партиягә яңа кабул ителгәннәрне тәрбияләү һәм аларны партия эшенә тартуга җитәрлек игтибар бирелмәү—җитди кимчелек булып тора.

Партия үзенең сафларын үстерү мәсьәләсендә бер вакытта да сан артыннан кумады һәм кумый. Иптәш Сталин 1924 нче елда ук XIII нче съезд йомгаклары турында өяз комитетлары секретарьлары курсында сөйләгән докладында болай диде: „Иң зур партияләр дә, әгәр дә алар мавыгып китсәләр, тиешеннән артык колачласалар һәм соңыннан колачлары җитмәслек, аны эшкәртә алмаслык булып чыксалар, һәлак булулары мөмкин". Иптәш Сталин шуңа күрә „Партиянең сыйфат составын яхшырту турындагы мәсьәләне кискен һәм ачык төстә куярга" кирәклекне таләп итте. Партиягә коллектив рәвештә кабул итәргә мөмкинме дигән сорауга җавап биреп, ул болай диде: „Партиягә керергә теләүче һәрбер кешегә карата якын килүнең сыналган методын—индивидуаль якын килүне һәм партиягә индивидуаль төстә кабул итүне партия саклап калырга тиеш. Безгә сан гына түгел, бәлки сыйфат та кирәк".

Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның партия турындагы өйрәтүләре, партия составын системалы рәвештә яхшырту турындагы, партиягә индивидуаль тәртиптә, тикшерелгән, коммунизм эшенә чын күңелдән бирелгән иптәшләрне генә сайлап алу турындагы күрсәтмәсе—барлык партоешмалар өчен закон булып тора. Партия оешмаларының бурычы—тстнаклылыкны, партия сафларының чисталыгын саклау, Ленин—Сталин партиясе члены дигән исемне һәм аның әһәмиятен югары тоту.

КҮКСАГЫЗДАН ЮГАРЫ УҢЫШ АЛУ ӨЧЕН

Татарстан АССР ның колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына, авыл хуҗалыгы белгечләренә һәм барлык җир органнары работникларына

КАУЧУК ҮСТЕРҮ ЭШЕ АЛДЫНГЫЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ЖИР ОРГАННАРЫ РАБОТНИКЛАРЫНЫҢ ӨЛКӘ КҮЛӘМЕНДӘГЕ КИҢӘШМӘСЕНЕҢ МӨРАҖӘГАТЕ

Иптәшләр! Безнең ил бик күп натураль каучук таләп итә, аңсыз промышленностьның әһәмиятле тармаклары, беренче чиратта, оборона промышленносте эш итә алмыйлар. ВКП(б) ның XVIII нче съезды—„Каучук продукциясен арттыруга аеруча игтибар итәргә“ директива бирде.

Илебездә чәчеп үстерелә торган каучук—күксагыз стахановча агрэтехника кулланган вакытта уңышны тропикада чәчеп үстерелә торган каучуктан ким бирми. Үткән елны Октябрь районы „Красная Гора“ колхозының иптәш Сидорова звеносы һәрбер гектардан уртача 32 центнер күксагыз тамры һәм 92 килограмм күксагыз орлыгы алды. Дәүләт бу колхозда житештерелгән һәрбер гектар уңышы өчен колхозга 11.226 шар сум акча түләде. Октябрь районының Сталин исемендәге колхозы быел ике еллык плантациянең һәрбер гектарыннан 168 килограмм орлык алды. Октябрь районының „Тебәк“ һәм Нәриман исемендәге колхозлары, Мамадыш районының „Прикамский“ колхозы һәм Шөгер районының „Кызыл Орден“ колхозы һәм башкаларда күксагыздан яхшы уңыш алдылар.

Мамадыш районы „Прикамский“ колхозының бригадиры иптәш Левенков яхшы производство күрсәткечләре өчен хөкүмәтебез тарафыннан „Хезмәттәге батырлык өчен“ медале белән, Октябрь районы Нәриманов исемендәге колхозның звено башлыгы иптәш Ибраһимова „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән бүләкләнделәр. Күксагыз алдынгыларыннан ун кеше быел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнаштылар.

Ләкин әле күксагыз эшенә игтибар итми торган колхозлар да аз түгел. Биләр, Актаныш, Минзәлә, Тельман районнары бары тик шуның сәбәпле генә күксагыздан бик түбән уңыш алдылар. Татарстан күксагыз тапшыру буенча дәүләт алдында үзенең йөкләмәләрен үтәмәде.

Күксагыз чәчәр өчен, еш кына, яраксыз, начар эшкәртелгән һәм аз тиресләнгән җирләр билгеләнә, минерал ашламаларга әһәмият бирелми, күксагыз чәчүлекләрен тәрбия итүдә агрономия кагыйдәләре күздә тотылмый. Күп кенә районнарда күксагыз игү эше звенолап оештырылмаган. Ә алдынгы колхозлар бары тик эшне звенолап оештыру аркасында гына күксагыздан зур уңыш алдылар.

Партия һәм хөкүмәтебез каучук үстерү эшенә гаять зур әһәмият бирәләр. Күксагыз өчен яхшы бәяләр куелган, күксагыз тамырын һәм орлыгын планнан тыш тапшырган өчен өстәмәләр—премияләр бирелә. Алдынгы колхозларга һәм яхшы колхозчыларга материаль артыклыклар күрсәтелә. Дәүләт колхозларга күксагыз орлыкларын түләүсез җибәрә, минераль ашламалар буенча махсус фондлар аерып куя, авансларга акчалар бирә. Күксагыз буенча югары һәм ныклы уңыш алу өчен бездә бөтен мөмкинлекләр күз алдында.

Без, каучук үстерү буенча өлкә күләмендә үткәрелгән киңәшмәгә катнашучылар, 1941 нче елда күксагыз уңышын: һәрбер гектардан кимендә 15 центнер күксагыз тамыры һәм 2 еллык чәчүлекнең һәрбер гектарыннан кимендә 25 килограмм күксагыз орлыгы алуга ирешү өчен йөкләмә алабыз һәм Татарстан АССР ның барлык колхозчыларын һәм авыл хуҗалыгы белгечләрен шуңа ирешергә чакырабыз. Моңа ирешү өчен барлык авыл хуҗалыгы артельләрендә энергияле һәм инициативалы колхозчылардан даими звенолар оештырыйк. Аларга участкыларны беркетик. Стахановчыл мәктәпләрдә һәм агротехника түгәрәкләрендә каучукчы стахановчыларның тәҗрибәләрен өйрәник һәм ул тәҗрибәләрне эшкә ашырыйк. Күксагызны иң яхшы җирләргә чәчик һәм чәчүлекләргә яхшы тәрбия күрсәтик.

Иптәшләр, колхозчылар һәм колхозчы хатын кызлар, социалистик ярышны киң җәелдереп, аңа барлык бригадаларны, звеноларны һәм һәрбер каучукчыны тартыйк. Без Башкыртстан АССР ның каучукчыларын ярышка чакырабыз. Бу ярышта Татарстанның өстенлеген яулап алыйк. Социалистик Ватаныбызга илебездә житештерелгән натураль каучукны күбрәк бирик, дәүләтебезнең оборона куәтен тагын да ныгытыйк.

Татарстан АССР алдынгы каучукчыларының өлкә күләмендәге киңәшмәсендә кабул ителде.

Колхозларда яңа фермалар

Татарстан колхозларында көмешсыман кара төлкеләр үрчетү буенча 17 яңа ферма оештыруга хәзерлек алып барыла. Колхозларда яңа оештырылачак фермалар өчен Бирюлидәге җәнлекчелек совхозы 67 баш төлке җибәрде. Тагын 50 баш төлке Көнбатыш Себердән кайтарылды. Яңа фермалар Алабуга, Әгерҗе, Этнә һәм Татарстандагы башка районнарда оештырылачак.

Яңа Писмән районында Уссурий еноты үрчетү буенча 3 яңа ферма оештырыла. Бу фермалар өчен енотлар Бөгелмә районының „Проточный ключ“ һәм Буденный исемендәге колхоз фермаларыннан кайтарылачак.

(ТатТАСС).

Чит илләрдә

Англия-Германия сугышы

ГЕРМАНИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

БЕРЛИН, 28 декабрь. (ТАСС). Германия армиясе верховный командованиесе сводкасында әйтелүенчә, рождество көннәрендәге тынлыктан соң 27 нче декабрьдә Германия авиациясе разведка очышларын һәм бомбага тотуларны яңадан башлаган. Темза тамагыннан көнчыгышка таба Германиянең бер разведка самолеты дошманның 8—10 мең регистр брутто-тонна чамасы авырлыктагы бер сәүдә карабына зиан китергән.

28 нче декабрьгә каршы төндә Германия авиациясенең зур берләшмәләре Лондонга һөҗүм иткәннәр һәм барлык калибрдагы бик күп фугаслы һәм яндыргыч бомбалар ташлаганнар.

Англиянең торпедоносец самолетлары Германиянең сакчы карабларына һөҗүм итмәкче булганнар, ләкин уңышсыз чыкканнар. Англиянең 3 самолеты бәреп төшерелгән. Англиянең тагын бер самолетын Германиянең зенит артиллериясе бәреп төшергән. Германиянең бер самолеты хәбәрсез югалган.

АНГЛИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

ЛОНДОН, 28 декабрь. (ТАСС). Рәсми рәвештә хәбәр ителүенчә, кичә кич Германия авиациясе Лондонга 4 сәгать буена һөҗүм ясаган. Төрле калибрдагы бомбалардан күп йортлар җимерелгән һәм зарарланган. Үлүчеләр һәм яралаучылар бар.

28 нче декабрьгә каршы төндә Англия самолетлары Франциянең немецләр оккупацияләгән территориясендәге докларны, аэродромнарны һәм су асты көймәләре базаларын, шул исәптән Бордоны, Лорианны, Гаврны бомбага тотканнар.

ЛОНДОН, 28 декабрь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, соңгы атнада (24 һәм 25 нче декабрьдән башка) Англиянең хәрби һава көчләре Германия оккупацияләгән территориядәге хәрби объектларга каршы киң операцияләрне дәвам иттергәннәр.

Сугыш башланганнан бирле беренче тапкыр Англия самолетлары Венеция якынында Порто ди Маргерадагы докларны һәм нефть чистарту заводларын бомбага тотканнар.

АНГЛИЯДӘ АЗЫК НОРМАЛАРЫН ЧИКЛӘҮ

НЬЮ-ЙОРК, 28 декабрь. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәренә караганда, азык белән тәэмин итү министре Вултон Англиядә ит сату нормасының тагын да кимителәчәген иглан итәчәк. Шулай ук рестораннарда да ит куллану нормасының кимителүен көтәләр. Азык белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча Англия экспертларының белдерүенчә, Англия складларында иң әһәмиятле азык продуктлары барсы да элеккечә җитәрлек санда.

Албания фронтында. Рәсемдә: Албаниядә Италиянең авиация базасы.

ТАСС фотосы.

1940 нчы ЕЛ АЗАГЫНА ГЕРМАНИЯ ПРОМЫШЛЕННОСТЕ

БЕРЛИН, 27 декабрь. (ТАСС). „Данцигер форпостен“ газетасы „Яңа ел алдыннан Германия промышленносте“ дигән исем астында мәкалә урнаштырды. Мәкаләдә болай диелә: „1940 нчы елны Германия промышленностенын хәл иткеч бурычы кораллану программасын үтәү булды. Шул уңай белән Германия промышленносте беренче чиратта эш көчләре тарту проблемасын хәл итәргә, предприятиеләрне кирәкле чимал белән тәэмин итәргә һәм финанс средстволары эзләп табарга тиеш булды.

Армиягә мобилизация нәтиҗәсендә эш көчләре җитешмәү сизелә башлады. Предприятиеләрне кирәкле эш көчләре белән тәэмин итү өчен 1 миллионнан артык ирләргә мобилизация ясалды. Болар 1940 нчы елның язында мәктәпне тәмам иткән яшьләр, шулай ук сугыш вактына яңадан үз профессияләренә керешкән пенсионерлар иде. Шулай ук немец хатын-кызлары да ирләр урнына килеп бастылар. Сугыш башланган вакытта производствога тартылган хатын-кызлардан тыш предприятиеләрдә тагын 200 меңнән артык хатын-кыз эшләячәк. Шуның өстенә эш көчләренә булган җитешмәүне бетерү өчен чит ил эшчеләре, шулай ук сугышта плән төшкән кешеләр тартылдылар. 1940 нчы елның сентябрендә промышленность предприятиеләрендә 400 меңнән артык чит ил эшчесе һәм 200 мең плен төшкән кешеләр эшләде. Күп кенә фирмалар үзләренең предприятиеләрен киңәйтә алдылар. Мәсәлән, „Гешу“ фирмасы зур прокат заводы салдырды һәм шуның өстенә яңа домна миче салдыра башлады. „Клекнэр“ фирмасы ике электр миче һәм яңа кокс миче салдырып, ванадий эшләп чыгара башлады. „Гуте Гоффнунгсхютте“ фирмасы үзенең машина төзү заводларын киңәйтте. Германия заводларын бушату теләге белән заказларның бер өлеше оккупацияләнгән өлкәләрдәге заводларга бирелде. Кораллар буенча махсус инспекцияләр оккупацияләнгән өлкәләрдәге предприятиеләрнең эшен күзәтеп торалар һәм алардан нәтиҗәле итеп файдалану турында кайгырталар.

Блокадага да карамастан предприятиеләрне чимал белән тәэмин итәргә мөмкин булды. Югары Силезиянең көнчыгыш районнарыннан күмер һәм Лотарингиядән тимер рудалары алу белән бер рәттән, дүрт еллык план белән күздә тотылган яңа заводларны салу аркасында да чимал базасы киңәйтелде.

Шуның өстенә Германиягә чимал Советлар Союзыннан, Ерак Көнчыгыштан, Якын Көнчыгыштан һәм континенттагы илләрдән сугышка кадәргегә карәганда күбрәк китерелә. Беренче чиратта Румыниядән һәм Россиядән нефть, Швециядән тимер рудасы, Россиядән мамык, Скандинавиядән целлюлоза, Италиядән һәм көньяк-көнчыгыш Европадан бокситлар китерелүне күрсәтергә кирәк.

Соңгы елларда Лотарингиядә 15 миллион тонна тимер рудасы чыгарылды. Немец белгечләре руда чыгаруны шактый арттырырга мөмкин дип саныйлар. 1938 нче елны Германия территориясендә (көнбатыш өлкәләрдән тыш) 233 миллион 600 мең тонна күмер һәм шуның өстенә 200 миллион тонна соры күмер чыгарылды“.

Промышленностька финанс бирү турындагы мәсьәләгә кагылып, „Данцигер форпостен“ газетасы, мәкаләнең ахрында болай дип яза: „1940 нчы елның январеннан октябренә кадәр барлыгы 835 миллион маркалык промышленность заемнары урнаштырылды. Шуның өстенә 641 миллион маркалык яңа акцияләр чыгарылды“.

Греция-Италия сугышы

БЕЛГРАД, 28 декабрь. „Политика“ газетасының Афинадагы хәбәрчесе, 25 һәм 26 нчы декабрьләрдә фронтның үзәк секторында бик каты сугыш башланып киткәнлекне хәбәр итә. Грек гаскәрләре берничә әһәмиятле позицияне алганнар. Әйтүләренә караганда, грекларның югалтулары артык зур түгел.

НЬЮ-ЙОРК, 28 декабрь. Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәренә караганда, Островице секторында Грек частьләре Москополедан төньяк-көнбатыштарак стратегик яктан бик әһәмиятле өч пунктны алганнар.

Англиянең һәм Грециянең 6 самолеты Валонаны бомбага тотып, шәһәргә шактый зур зиан китергәннәр. Шулай ук Валонадан төньяктарак булган Киркавада бензин складлары да бомбага тотылган.

Осум елгасы секторында греклар бик озак бомбага тотканнан соң Вирея авылын алганнар. Сугыш вактында греклар 22 кешеләрен югалтканнар. Итальяннардан 25 кеше үтерелгән һәм 121 кеше плен төшкән.

Төньякта грек частьләре Эльбасанга бара торган олы юл буйлап баралар һәм хәзер Кьюкса тирәсендә торалар.

Клисура секторында греклар Требешине тауларында операцияләрне тәмам итеп киләләр. Тепелене секторында грек гаскәрләре Тепеленедән 10 миль төньяк-көнбатыштарак Точи авылына барып җиткәннәр.

Италия флоты Адриатика диңгезенең төньяк өлешендә Пола һәм Фиуме портларына тупланган.

НЬЮ-ЙОРК, 28 декабрь. Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, грек гаскәрләренең Лин шәһәрен алулары турындагы хәбәрне Греция хөкүмәте юкка чыгара. Яр буе районында греклар Валона бухтасыннан көньякка таба 5 миль ераклыктагы бер авылны алганнар. Москополедан көньяк-көнбатышта греклар Островице биеклеге янында итальяннарның 3 позициясен алганнар. Италия самолетлары Корфуга һөҗүм итеп, 10 бомба ташлаганнар. Превезуга 200 бомба ташланган. (ТАСС).

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

— Кубаның Бехукал шәһәре якынында гадәттән тыш көчле давыл булган. 40 кеше үлгән, 100 дән артык кеше яраланган.

— Сан-Францискода су асты көймәләре өчен яңа йөзмә база эшләнгән. База срогыннан 19 ай элек тәмам булган. Ул 12 миллион долларга төшкән.

— АКШ тагы кытайлар Кытай хәрби авиациясе фондына Америка доллары белән 6 миллион 400 мең доллар акча җыйганнар.

— Соңгы 3 ай эчендә Франциянең Пюи-де-Дом департаменты полициясе 20 ләп кешене, агитация һәм листовкалар тараткан өчен кулга алган.

БИБЛИОГРАФИЯ

МИХАИЛ ИВАНОВИЧ КАЛИНИН ТУРЫНДА КИТАП*)

Совет кешеләре Лениннең һәм Сталинның һәм аларның көрәштәшләренең тормышын һәм революцион эшен тирән игтибар белән өйрәнәләр. Бу бик аңлаешлы, чөнки алар Лениннән һәм Сталиннан, аларның якын көрәштәшләреннән—Ленин—Сталин типындагы политик эшлеклеләрдән—ничек яшәргә һәм коммунизмның бөек идеаллары өчен, коммунистик җәмгыять өчен ничек көрәшергә кирәклеккә өйрәнәләр.

М. И. Калининның тормышы турында Ленинград ВКП(б) Тарихы Институты төзегән китапны укучыбызга бик яхшы бүләк дип атарга мөмкин *). 65 еллык тормыш һәм эшчеләр сыйнфы сафларында 40 елдан артык дәвам иткән революцион көрәш—бу, данлыклы, героик ун еллыклар тарихы, большевиклар партиясенең тууы һәм оешуы тарихы, өч революция, самодержавиене һәм капитализмны бәреп төшерү, илебездә социалистик җәмгыять төзелеше тарихы. Үткән гасыр ахрыннан башлап М. И. Калинин шушы бөтен тарихи чор буена эшчеләр сыйнфының һәм аның партиясенең беренче сафларында булды.

М. И. Калинин 1875 нче елны Тверь губернасының Верхная Троица авылында, аз җирле крестьян семьясендә туа. Аның атасы эш эзләп һәр вакыт авылдан китә торган була. Хуҗалыктагы бөтен эш ана җилкәсенә һәм бала вактыннан ук эшли башлаган Михаил Иванович өстенә төшә. Михаил Калинин тугызынчы яше киткәндә бер отставной солдаттан укый башлый, ә унбер яшендә земство мәктәбенә керә. 1889 нчы елны, мәктәпне тәмам иткәннән соң, 14 яшендә чагында ул алпавытта „малай“ булып эшли. Шул ук елны алпавыт семьясе Петербургка күчә һәм М. И. Калинин да аның белән китә. Шуннан соң ул алпавытта тагын 4 ел эшли.

Күп нәрсәләр белергә яратучы егет алдында яңа дөнья ачыла. Ул башкаладан бик нык тәэсир ала, алпавытның көтепханәсендәге китапларны—матур әдәбияттан алып политик экономиягә һәм философиягә кадәр барсын да бербер артлы укып чыга. Калинин укыган китаплар арасында Герменның „Полярная звезда“, „С того берега“ дигән әсәрләре кебек яшерен әдәбият та була.

Шулай итеп М. И. Калининның политик карашлары бер-бер артлы бер форма ала башлыйлар. 1893 нче елны ул патроннар ясый торган „Старый арсенал“ заводына өйрәнчек булып керә һәм шунда эшчеләрнең яшерен түгәрәкләре барлыкны белә. 18 яшьлек яшь эшче Михаил Калинин революцион оешма белән элемтә урнаштырырга тырыша, ләкин ул моны 1896 нчы елдан соң гына, Нарва заставасы артында Путилов заводының пушка мастерскоена эшкә күчкәч кенә эшли ала.

1898 нче елның башында Калинин революцион подполье белән элемтә урнаштыра һәм „Путиловец“ та революцион марксистик түгәрәк төзи башлый. Күп һәм һәр вакыт китаплар укыган Калинин түгәрәкнең җаны була. Түгәрәктә катнашучылар Маркс һәм Энгельснең „Коммунистик манифест“ ын, Маркснык „Ялланган хезмәт һәм капитал“ ын, Франциядә е буржуаз революция турындагы китапларны, Германиядә эшчеләр хәрәкәте тарихы турындагы һ. б. әсәрләрне өйрәнләр. Озак та үтми Калинин түгәрәге путиловчы эшчеләрнең көрәшенә җитәкчелек итә башлый һәм бераз вакыт үткәч чынлыкта Питердагы иң зур ике районның революцион эш үзәге булып әверелә.

Шулай итеп М. И. Калинин пролетар революционер юлына, патша Россиясе шартларында гаять күп кыенлыкларга бәйләнгән юлга керә.

Калининны берничә тапкыр кулга алалар, төрмәләргә ябалар, сөргенгә җибәрәләр, тентиләр, кыйныйлар, заводлардан куып чыгаралар. Полиция һәм жандармнар тарафыннан эзәрлекләнгән хәлдә ул бер урыннан икенче урынга күчә, квартирадан квартирага һәм шәһәрдән-шәһәргә күчеп йөри. Ләкин аның бөгелмәслек резолюцион омтылышын бер нәрсә дә сындыра алмый. М. И. Калинин ирекка чыгу белән үк эшчеләрве яңадан оештыра, пропаганда һәм агитация эше алып бара, стачкаларга җитәкчелек итә, яшерен әдәбият тарата, листовкалар яза. Ул Ленин „Искра“ сының вәкиле, партиянең Петербург комитеты члены, пропагандист агитатор, массаны оештыручы була.

Партиянең IV нче съездына делегат булып баргач, 1906 нчы елны ул Стокһольмдә Ленин һәм Сталин белән очраша һәм таныша. 1912 нче елны большевикларны мөстәкыйль марксистик партия итеп оештырган Прага конференциясендә М. И. Калинин Үзәк Комитет членлыгына кандидат итеп һәм Үзәк Комитетның иптәш Сталин җитәкчелегендәге Россия бюросының члены итеп сайлана. 1913 нче елны Үзәк Комитетның Поронинода партияле работниклар белән булган киңәшмәсендә Калининны Үзәк Комитет членнары составына кертәләр. Шул ук елны Калинин, турыдан-туры иптәш Сталин җитәкчелегендә, IV нче Дәүләт Думасына сайлау кампаниясендә катнаша, „Правда“га җитәкчелек итүдә Сталин һәм Молотов иптәшләргә булышлык итә. Империалистик сугыш елларында М. И. Калинин эзлекле ленинчел—сталинчыл политика алып бара, меньшевикларга һәм эсерларга каршы көрәшә.

Февраль революциясенең беренче көннәреннән үк Калинин партиянең гомуми шәһәр үзәгенә сайлана һәм „Правда“ редакциясе составына кертелә. Ленин эмиграциядә, Сталин сөргендә була. Иптәш Сталин сөргеннән кайтканчыга кадәр Молотов һәм Калинин иптәшләр өстенә Үзәк Комитетның Россия бюросының, Петербург комитетының бөтен эшенә һәм „Правда“ га җитәкчелек итү йөкләнә.

М. И. Калинин Октябрь революциясен хәзерләүдә якыннан торып һәм актив катнашты. Аның квартирасында Үзәк Комитетның Ленин һәм Сталин катнашы белән яшерен утырышлары булды.

1919 нчы елның мартында Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты председателе Я. М. Свердлов үлә. В. И. Ленин тәклифе буенча Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты председателе итеп М. И. Калинин сайлана. М. И. Калинин кандидатурасын күрсәткәндә Ленин аның зур тормыш тәҗрибәсе барлыкны, эшчеләр һәм крестьяннар белән элемтәсе барлыкны, ә моның эшчеләр сыйнфының крестьяннар белән союзын ныгыту өчен бик әһәмиятле икәнлеген аеруча күрсәтеп үтә.

Шул вакыттан бирле М. И. Калинин егерме елдан артык вакыт буена Совет властеның югары вәкиле постында тора. Социалистик төзелештә совет халкының бөтен көрәше, барлык җиңүләре Лениннең һәм Сталинның якын шәкертләреннән һәм көрәштәшләреннән берсе булган М. И. Калинин исеме белән бәйләнгәннәр.

Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армияне политик агартуда М. И. Калининның роле шактый зур булды.

Михаил Иванович совет республикалары Союзын ныгыту өстендә, СССР халыкларының ленинчелсталинчыл дуслыгын ныгыту өстендә җиң сызганып эшли. СССР төзелгәннән соң М. И. Калинин күп кенә республикаларда булып кайта—Азәрбәйҗанда, Чечен-Ингушиядә, Төньяк Осетиядә, Башкыртстанда һ. б. була—Ленин—Сталин милли политикасының магнәсен аңлата.

Ул партия съездларында һәм конференцияләрендә, Советлар съездларында, эшчеләр, крестьяннәр һәм хезмәткәрләр җыелышларында докладчы булып чыга. Иң катлаулы фикерне дә, иң катлаулы теоретик положениене дә М. И. Калинин гади генә һәм аңлаешлы итеп сөйләп бирә ала.

Ленинизм дошманнары—троцкичылар, зиновьевчылар, бухаринчылар—илебезне социалистик төзелеш юлыннан читкә чыгарырга маташтылар, партиядә һәм эшчеләр сыйнфында үз көченә ышанмауны җәелдерергә омтылдылар. Иптәш Калинин дошманнарга каты ударлар ясады. Партиянең XIV нче съездыннан соң ул, Үзәк Комитетның башка членнары белән—Молотов, Ворошилов, Киров, Андреев иптәшләр белән берлектә, троцкичы-зиновьевчы шайканың позицияләре большевизмга каршы, җинаятьчел характерда икәнлекне партиянең Ленинград оешмасы членнарына аңлату өчен Ленинградка килде. Партиянең XV нче съездында М. И. Калинин троцкичыларга һәм зиновьевчыларга каршы кискен речь белән чыга һәм аларны партиядән кискенлек белән куууны таләп итә.

Революцион уяулык, принципиаллык, килешмәүчәнлек, партиянең дошманнарына карата рәхимсезлек—М. И. Калининның аны аерып тора торган сыйфатлары.

Докладларында, речьләрендә, мәкаләләрендә, хезмәт ияләре белән булган беседаларында Михаил Иванович Сталинчыл индустрияләштерү һәм коллективлаштыру планнарын гади беседа формасында, ышандырырлык һәм аңлаешлы итеп пропагандалый, СССР ның оборона һәм хуҗалык куәтен ныгыту турында, капиталистик чолганыш куркынычын истә тотып уяу булырга кирәклек турында, һәрбер кешенең яхшырак, инициативалырак, нәтиҗәлерәк эшләргә, үзендә хезмәткә, коллективка, җәмгыяткә мәхәббәт тәрбияләргә тиешлеге турында сөйли.

Аның речьләре һәм мәкаләләре зур тормыш акылы белән, тирән халыкчыллык белән, массага якынлык белән, массаның нәрсә белән яшәвен искиткеч төстә белү белән аерылып торалар. Күп белемле марксист, күп яклы һәм тирән белемнәре булган М. И. Калинин теоретик положениеләрне социалистик төзелешнең практик бурычлары белән бергә бәйли.

М. И. Калинин турындагы китапка эпиграф итеп Михаил Ивановичның түбәндәге сүзләре алынган: „Минем тормышымның бөтен тарихы, ә чынлыкта эшчеләр сыйнфының бөтен тарихы шуннан гыйбарәт ки, без Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә яшәдек һәм көрәштек“.

М. И. Калинин турындагы китап әнә шуны күрсәтә дә.

П. Мор.

*) Михаил Иванович Калинин. ВКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Политиздат. 1940 ел. 127 бит. Тиражы 300.000. Бәясе—төпләнгәне 2 сум 20 тиен, төпләнмәгәне 1 сум.

СОҢГЫ ПОЧТАДАН

ХАЛТУРА

Шушы арада „Кызыл Эш“ (Зәинский районы) газетасында „Ташкыннар“ дигән рус сәхнәсендә“ дигән баш астында „рецензия“ басылып чыкты.

— Туктагыз әле, Тәжи Гыйззәтнең „Ташкыннар“ы рус телендә куелдымы икән, дип укый башлагач, мәсьәлә аңлашылды. Яңа түгел „рецензент“ В. Тарасов (ул ук В. Багряшевский да), татар спектакле рус авылы клубының сәхнәсендә куелганны шулай атаган булып чыкты. Югары Багряж һәм Бигеш авылларының татар укытучылары Зәинскийга килеп спектакль куйганнар икәнбик яхшы эшләгәннәр.

Аңсы аңлашыла.

Ләкин менә: „Касимхан роленда уйнаучы иптәш Фролов үзен сәхнәдә шундый „иркен“ тота, әйтерсең ул яңа дөньясын оныткан, әйтерсең анның өчен бар да „пешкән дә төшкән“ дигән сүзләрне ничек аңларга?

Без төрлечә уйлап карадык. Фролов сәхнәгә чыгып ни эшләде икән, йоклап утырганмы ул, суфлер әйткәннәргә тыңламыйча сәхнәдә җаныңа кунгарып йөргәнме, әллә сәхнәдә башка берәр төрле, сәхнәдә эшләп чыктымы икән? Үзен курмәгәч, Фроловның сәхнәдәге кыланышларын, аның ничек итеп „дөньясы онытып“ күз алдына китерү читен, әлбәттә.

Менә башка нәрсә булырга тиеш. Икенең бете „рецензент“ я спектакль карамаган, я булмаса бу рецензияне язган чагында үзе „дөньясын оныткан“ булган. Ничек кенә булмасын—сәхнәдә рецензия түгел, халтура килеп чыккан. Бутлап „рецензия“ гомумән спектакльгә ни өчен яхшы баа бирелганлекне да аңлап булмый.

Аннан соң В. Тарасов—В. Багряшевский, Бикчәнтер ролен башкаручы Габитовның сәхнәдәге кыяфәтен совет сәхнәсенә чит булган, тамашачыларны читен хәлдә калдыргач курнеш итеп тасвирлаган. Инде узе шул ук кыяфәтне „урам сүзләре“ белән тасвир итеп, газета битенә язып чыккан. Совет сәхнәсенә чит булган нәрсәне большевистик матбугат битенә язарга ярамаганлыкны автор уйламаганмы, әллә моңда да узе „дөньясын оныткан“ булганмы...

„Кызыл Эш“ газетасының җаваплы редакторы өчен күл куючы иптәш Колчерин дә сенсацияле баш астында халтура һәм парнография ятканны, һәм язып китергән бер нәрсәне, тикшерми торып, газетага урнаштырырга ярамаганлыкны аңламаган, күрәсең!

35 нче номерлы мәктәпнең (Казан) бөтен фәннәр буенча отличнога укучылары Габдрахман Гайнуллин (стена газетасы редакторы) һәм Һәҗәр Кулиева (пионер отряды вожатые). И. Галиев фотосы.

ЯҢА ЕЛ ЕЛКАЛАРЫ

Әгерҗе районында яңа ел елкаларын утыруга зур хәзерлек алып барыла. Районның сәүдә оешмалары бу көнне үткәрү өчен мәктәпләргә кирәкле товарлар белән тәэмин итәргә конкрет чаралар күрәләр. Ижбуби авылы урта мәктәбендә елкага хәзерлек уңае белән укучыларның кыллы оркестр түгәрәге оештырылды. 1 нче январьда бу мәктәптә балалар өчен зур концерт куела.

Кочек авылы тулы булмаган урта мәктәбе укытучылары һәм укучылары шушы көннәрдә Мирхәйдәр Фәйзинең „Галиябану“ пьесасын куйдылар.

Районның Сарсак Омга, Тирсә авылындагы „Татарстан“, Кигов исемендәге колхозларның урта мәктәпләрендә елкага хәзерлек уңае белән чаңгыда йөрүләр оештырылды.

Район үзәгендә булган урта һәм тулы булмаган урта мәктәпләрдә елкалар зур һәм маскарад үткәрелә. Әгерҗе шәһәренең Ленин исемендәге клубында бал-маскарад уздырылачак.

Районның мәктәпләрендә балалар катнашачак. Монда мең балага өчен бик яхшы итеп курсәтелә. Елка кую өчен мәктәп иптәшләр өчен 3 бүләк билгеләнде.

***

Кышкы каникул вактында—2 нче январьдан алып 12 сенә кадәр—Казандагы мехчылар клубының зур залында балалар өчен көн саен елка булачак. 10 мең балага хезмәт күрсәтү билгеләнә. Елкалар оештыру һәм балаларга бүләк хәзерләү өчен мехчылар союзының район комитеты һәм Мехкомбинат 7 мең сум акча билгеләделәр.

АЛБАНИЯДӘГЕ ҺӘМ ЛИВИЯДӘГЕ СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕН КҮЗӘТҮ

21 НЧЕ ДЕКАБРЬДӘН 28 ЕНӘ КАДӘР

Албаниядә грек гаскәрләре инициативаны кулларыннан ычкындырмыйлар. Иң каты сугышлар фронтның көньяк өлешендә бара. Анда ике атнадан бирле инде греклар Италия гаскәрләренең Валонага һәм Бератка бара торган юлны каплап тора торган төп оборона линияләрен өзәргә тырышалар. Грек гаскәрләренең Клисурага, Тепеленегә һәм Химарага фронттан ясаган атакаларын итальяннар кире кайтардылар. Шуннан соң грек частьләре итальяннарның каршылык күрсәтүләренең төп узелларын әйләнеп үтәргә тырышып карадылар. Моның өчен алар таулар арасындагы тар сукмаклардан файдаландылар. Шушындый маневр аркасында греклар 22 нче декабрьдә Химараны алдылар һәм шулай итеп Италиянең оборона линиясенең уң флангысын өзделәр. Италия частьләре Валонага якын булган соңгы оборона линиясенә чигенделәр. Грек гаскәрләре дошманны куып баруларында дәвам итәләр һәм шул ук вакытта Тепеленене һәм Клисураны саклаучы Италия гаскәрләренең тылына куркыныч тудыралар. Греклар Клисура шәһәрен яртылаш чолгап алганнар инде һәм Клисура белән Берат арасындагы юлны кискәннәр.

Фронтның төньяк өлешендә сугышучы якларның хәле үзгәрешсез. Грек гаскәрләренең итальяннарның оборонасын өзәргә һәм Эльбасан белән Лин арасындагы юлга барып чыгарга тырышулары нәтиҗәсез булды. Фронтның бу участкысының вакытлыча нык торуының төп сәбәбе—Италия гаскәрләренең яңа килгән частьләр белән көчәйтелүендә, Италиянең, бигрәк тә авыр артиллериясенең өстен булуында һәм, ниһаять, моңа шулай ук һава шартлары да ярдәм итәләр. Мокра һәм Камна тауларында яуган тирән кар, көчле салкыннар һәм җилләр сугышучы якларның һәр икесенең дә хәрәкәтләренә начар йогынты ясыйлар.

Англия-Греция авиациясе, һөҗүм итүче гаскәрләргә булышлык итү белән бергә, Валонага, Бератка һәм Италия гаскәрләренең тылындагы башка пунктларга берничә тапкыр һөҗүмнәр ясады. Италия авиациясе Грециянең Флорина, Корфу шәһәрләрен, шулай ук Флорина-Корча юлындагы транспортларны бомбага тотты.

***

Ливиядә сугыш хәрәкәтләре нигездә итальяннарның Бардия крепосте тирәсендә бара. Соллумнан чигенеп баручы, генерал Бергонцоли командасы астындагы Италия гаскәрләре хәзер Бардия фортлары артында оборонада торалар. Англиянең моторлаштырылган частьләре крепостька барып керә алмадылар. Шунлыктан алар яңа частьләр һәм авыр артиллерия килүне көтеп торырга мәҗбүр булдылар. Бардияга хәлиткеч һөҗүм ясау соңгы берничә көн буена хәзерләнә, инде һәм бу хәзерлек Англиянең диңгез һәм һава көчләренең Бардияны бер туктаусыз бомбага тотуларында күренә.

Майор *Е. Ссснин.*

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

Үзәк Кытайда. Соңгы көннәрдә күп кенә районнарда япон гаскәрләре тылында партизаннар отрядлары активлашканнар. Күптән түгел кытай партизаннары Янцзы елгасының төньяк ярында, Нанкинга каршы урнашкан Цзянпу шәһәренә һөҗүм иткәннәр. Партизаннар оборонаның тышкы линиясендә япон частьләренең каршылыгын җиңеп шәһәргә кергәннәр һәм бераз гына урам сугышыннан соң японнарның күп кенә учреждениеләрен яндырганнар, ә соңыннан шәһәрдән чыгып киткәннәр.

21 нче декабрьдә кытай партизаннары Пукоу—Хэфэй тимер юлында японнарның бер хәрби поездын шартлатканнар. (ТАСС).

Редакциягә килгән хатлардан

КОЛХОЗНЫҢ БҮЛЕНМИ ТОРГАН ФОНДЫННАН ДӨРЕС ФАЙДАЛАНЫРГА

Әлки районының күп кенә колхозларында бүленми торган фондны дөрес файдалануга тиешле әһәмият бирмиләр. Колхозлар, авыл хуҗалыгы артеле уставы нигезендә, үзләренең финанс доходларының 12—15 процентын бүленми торган фондка күчерергә тиешләр. Ләкин районда кайбер колхозларның җитәкчеләре бу тәртипне бозалар. Бу фондны киметүгә һәм тиешсез урыннарга тотуга юл куялар.

К. Маркс исемендәге колхоз (председателе иптәш Кәлимуллин) быел бүленми торган фондка колхозның финанс доходыннан 13.330 сум акча күчерергә тиеш булса да, бары 8.741 сум гына акча күчергән. Шуның өстенә, бүленми торган фондтан кире кайтару шарты белән вакытлыча алынган 11.175 сум акча дәүләт банкысына кертелмәгән. Шулай итеп, колхозның бүленми торган фондыннан 15.764 сум акча эчке расходларга тотылган.

„Туры юл“, „Динамо“ һәм башка күп кенә колхозларда да шушындый ук хәл.

Бүленми торган фондларны дәүләт банкысына кертмичә, турыдан-туры тоту фактлары да күп. Мәсәлән, „Туры юл“ колхозы (председателе иптәш Зарипов) 5.700 сум, „Кызыл Байрак“ колхозы (председателе Яруллин) 6.100 сум акчаны дәүләт банкысына кертмичә урынсызга тотканнар.

Әлки районында бу мөһим мәсьәләгә гомумән җидди игтибар бирүче юк. Шуның нәтиҗәсендә колхозларның финанс доходларыннан тиешле процентларны бүленми торган фондларга күчерү узган елда 72 процент, ә быел бары 20 процент кына үтәлде.

„Красный хлебороб“ колхозы быелгы финанс доходыннан бүленми торган фондка 12—15 процент урнына, бары 10 процент кына күчергән. МТС директоры Сәйфеттинов, район җир бүлеге мөдире Гобәйдуллин иптәшләр бу кимчелекләрне үз вактында төзәтүгә игтибар итмәгәннәр.

Н. Гобәйдуллин.

УЧЕТ ЭШЕ БУТАЛГАН

Питрәч районы, „Объединение“ колхозының дәүләткә окладлы страхование буенча 2.568 сум, доход налогы буенча 360 сум бирәчәге бар. Колхоз җитәкчеләре бу алачакларны җыеп алу чараларын күрми. Шулай ук колхозда финанс дисциплинасын бозу фактлары да бар. Мәсәлән, расходларның 45 проценты дәүләт банкысының рөхсәтеннән башка тотылган.

Колхозда гомумән учет эше начар куелган. Бухгалтерея кенәгәләре дөрес тутырылмыйлар. Колхозчыларның хезмәт көннәре кенәгәләргә үз вактында язылмыйлар.

Октябрь аенда үткәрелгән тикшерү вактында 1.192 сумлык акча документлары тикшерү комиссиясе тарафыннан кабул ителмәгән иде. Бу эш әле шушы көнгә кадәр хәл ителгәне юк. Колхоз председателе Ларионов моннан ике ай элек колхоздан алган 502 сум акчаны кайтарып бирү турында уйлап та карамый. Колхозда хезмәт дисциплинасын ныгыту һәм учет эшендәге мондый җитешсезлекләрне бетерү урнына, колхоз председателе Ларионов һәм хисапчы Хохлов эчүчелек белән шөгыльләнәләр. 20—21 нче декабрь көннәрендә эчеп йөреп, бөтенләй эшкә чыкмадылар.

Авыл советы председателе иптәш Клеопатров бу баш-баштаклыкларга күз салмый. *М. Шаһиев.*

СТАХАНОВЧЫЛАР МӘКТӘПЛӘРЕНӘ ИГТИБАРНЫ КӨЧӘЙТЕРГӘ

Колхозларда югары һәм ныклы игеп уңышы алу юлларын колхозчыларга өйрәтүдә стахановчылар мәктәпләре гаят зур урын тоталар. Ләкин, безнең Әгерҗе районында бу мәсьәләгә җитәрлек игтибар бирелми. Хәзерге көндә районның бары 13 колхозында гына стахановчылар мәктәпләре бар. 35 колхозда агрономия һәм зоотехника укулары бөтенләй алып барылмый.

Колхозларда стахановчылар мәктәпләренә башлыча колхоз агротехниклары җитәкчелек итәләр. Шуңа күрә, ул мәктәпләрдә эшнең уңышлы баруын тәэмин итү өчен колхоз агротехниклары белән системалы рәвештә шөгыльләнергә, аларга мәктәпләрдә дәресләрне оештыруда практик булышлык күрсәтергә кирәк. Әгерҗе районында бу эш тә онтылган. Районда 19 агротехник бар. Район җир бүлеге һәм МТС ның баш агрономнары агротехникларны җыеп сөйләшкәннәре дә юк.

Стахановчылар мәктәпләре мәсьәләсе белән Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты да җитәрлек шөгыльләнми. Колхозлардагы стахановчылар мәктәпләре өчен программа да юк, стабель дәреслекләргә дә кытлык бик зур.

Агроном С. Юнай.

УКУ ӨЙЛӘРЕНӘ ИГТИБАРНЫ КӨЧӘЙТЕРГӘ

Үзләренең эшләрен үрнәк булырлык итеп куйган политик-агарту учреждениеләре безнең республикада күпләп санала. Урыннардагы партоешмалар, җирле Советлар, комсомол оешмалары аларның эшләренә турыдан-туры җитәкчелек иткән авылларда клублар һәм уку өйләре яхшы эшлиләр. Андыйлардан Красный Бор районының Балтач, Ямурза, Кичкутан авылларындагы уку өйләрен, Ширәмәт районының Нәриманов исемендәге колхозы клубын, Яңа Писмән районының Михайловка уку өен һәм башка бик күпләрне күрсәтергә мөмкин.

Партия, совет оешмалары аз игтибар иткән урыннарда исә эш киресенчә. Менә Бондюг районының Сәйтәк авылы клубы. Аның инде 5—6 елдан бирле ремонт күргәне юк. Аның шундый ташландык хәлдә булуы, андагы салкынлык, әлбәттә, культура-масса, тәрбия эше алып барырга мөмкинлек бирми.

Ширәмәт районының Балчыклы авылы уку өендә дә канәгатьләнерлек эш җәелдерү өчен мөмкинлек юк. Авыл советы башкарма комитеты (председателе Константинов) уку өенә игтибар бирми.

Менә мондый уку өйләрен бүгенге көн сорауларына җавап бирерлек итеп эшләтү өчен район оешмаларының катнашуы кирәк. *Х. Шиһапов.*

Фрунзе исемендәге колхозда (Кант районы, Кыргызстан ССР) электростанция эксплоатациягә бирелде. Рәсемдә: колхозчы Чичеза Шабаза электр утюгыннан файдалана.

А. Бахвалов фотосы (ТАСС).

СССР да

КАРПАТ ТАУЛАРЫНДА ЗАПОВЕДНИКЛАР

Украина ССР Совнаркомы карары буенча Карпат тауларында (Станислав өлкәсе) дәүләтнең яңа заповедниклары оештырылды. 66 мең гектар мәйдан биләп тора торган „Черногора“ заповедникы Прут һәм Черемош елгалары арасында тау тезмәләре бетенә урнашкан. Аның территориясендә бик зур чыршы урманнары бар. Черемош елгасы башлана торган урында Европада иң зур булган нарат урманы урнашкан. Анда бик күп аюлар, боланнар, кабаннар, бүреләр һәм сусар, кама, тиен кебек кыйммәтле мехлы җәнлекләр яши. 50 мең гектар урын алып тора торган „Горганы“ заповедникы Украинада эрбет агачлары бик күп булган урын булуы белән атаклы.

„XIX НЧЫ ГАСЫР ДИПЛОМАТЛАРЫ“ ТЕМАСЫНА ЛЕКЦИЯЛӘР

ВКП(б) ның Ленинград шәһәр комитеты январь аенда „XIX нчы гасыр дипломатлары“ дигән темада лекцияләр үткәрә башлый. Лекцияләрне тыңлаучылар күп кенә капиталистик илләр хөкүмәтләренең тышкы политикасындагы төп фактлар белән, шулай ук Талейран, Меттерних, Пальмерстон, Биконсфильд, Горчаков һәм Бисмарк кебек иң күренекле дипломатларның эшләре белән танышачаклар.

„ПРОИЗВОДСТВЕННОЕ ОБУЧЕНИЕ“ ЖУРНАЛЫ

1941 нче елның январеннан башлап Хезмәт Резервлары Баш Идарәсе „Производственное обучение“ исемле журнал чыгара башлый. Журнал фабрика-завод өйрәнчеклеге мәктәпләре, һөнәр һәм тимер юл училищеләре директорларына, мастерларына, укытучыларына һәм укыту производство бүлеге мөдирләренә карап чыгарыла. Журнал аена бер тапкыр чыгачак.

КАЛУГАДА ВИНОГРАД

Калуга мичуринчысы В. В Остроумов моннан утыз ике ел элек Кырымдагы виноград питомникларыннан 5 төп виноград алып кайткан һәм Калугада виноград үстерә башлаган. Хәзер аның кечкенә генә бакчасы чын лабораториягә әйләнгән. Хәзер Остроумов бер куактан 20 килограммга кадәр виноград алуга ирешү бурычын куя. Анардан үрнәк алып башка мичуринчылар да шулай ук виноград үстерә башлаганнар.

ТЕАТРЛАРДА

Татарстанның дәүләт курчак театрында спектакльләр бирү өчен рус һәм татар группалары эшли. Каникул көннәрендә Казанда рус группасы тарафыннан курчак театрында, мәктәпләрдә һәм клубларда һәр көн 4 әр спектакль биреләчәк. Коллыктан азат булу өчен халыкның көрәшен күрсәтә торган „Зур Иван“ һәм батырлык турында сөйли торган „Тылсымлы галош“ пьесалары уйналачак.

Татар группасы хәзерге көндә районнарда эшли. Ул каникул көннәрендә Ютазы, Әлмәт, Азнакай районнарындагы колхозларда спектакльләр бирәчәк. Мәктәпләр курчак театрына культпоходлар оештыралар.

***

Яшь тамашачылар театры 1 нче январьдан алып 12 сенә кадәр һәр көн икешәр спектакль бирә. Тәнәфес вакытларында спектакльләр турында беседалар үткәреләчәк. Театр артистлары мәктәпләрдәге үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләренең эшләрен оештыру турында консультацияләр алып баралар. Каникул көннәрендә яшь тамашачылар театры 10 меңгә якын балага хезмәт күрсәтәчәк.

Шуның өстенә театр артистлары җитәкчелегендә кайбер мәктәпләрдә үзешчәнлек сәнгате көчләре тарафыннан спектакльләр, концертлар биреләчәк.

ЯҢА ЯСЛЕЛӘР

Шушы көннәрдә Казанның фото-желатин заводында эшләүчеләрнең балалары өчен 60 койкалы яңа ясле ачылды. Январь башларында Ленин районында яңадан 120 койкалы ясле ачыла. Хәзерге көндә шәһәрнең төрле районнарында барлыгы 37 ясле эшли. Аларда 2.929 койка бар. Барлык ясләләр квалификацияле врачлар, сестралар белән, шулай ук җиһазлар белән тәэмин ителделәр.

КЫСКА ХӘБӘРЛӘР

— 1940 нчы елда Ютазы авылында эшчеләр, хезмәткәрләр һәм колхозчылар үзләренә 71 яңа йорт төзеделәр. 1935 нче елдан, ягъни Ютазы авылы район үзәге булып әверелгәннән соң, анда 211 яңа йорт төзелде.

— „15 лет Октября“ артеле (Әгерҗе) еллык планны срогыннан элек үтәде. Еллык план буенча билгеләнгән 395 мең сум урнына, артель 20 нче декабрьгә 450 мең сумлык продукция эшләп чыгарды.

— Татарстан районнарындагы 15 авыл больницасы быел клиника диагностика лабораторияләре алды. Хәзер Татарстанда бөтенесе шундый 61 лаборатория исәпләнә.

— Татарстанның геология-разведка тресты янында фәнни-тикшеренү лабораториясе оештырылды. Бу лабораториядә химия, петрография һәм палеонтология кабинетлары бар. Лаборатория 2.500 дән артык тикшерү эшләре үткәрде инде. Лаборатория Шөгер һәм Кама Тамагы скважиналарыннан алынган шлифларны тикшерә. (ТатТАСС).

БЕЛДЕРҮ

Бүген кич сәгать 7 дә ВКП(б) ның Молотов райкомы парткабинетында (Комлев урамы, Хезмәт сарае, бүлмә № 2) Молотов районы өчен В. И. Ленинның „Империализм капитализмның иң югары стадиясе“ дигән әсәре турында лекция була. Лектор—иптәш Шевцов. Лекциягә керү түләүсез.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответственный редактор
Х. АБДРАХМАНОВ.

ГЛАВКИНОПРОКАТНЫҢ ТАТАРСТАН КОНТОРАСЫ
якын көннәрдә Татарстан кинотеатрлары экраннарына
„ЯҢА ДӨНЬЯНЫҢ БЕР КӨНЕ“



ТАТАРСТАН АССР НАРКОМФИНЫ
барлык предприятиеләргә, учреждениеләргә, оешмаларга һәм промысло-кооператив артельләренә
белдерә,

ЗАГОТКОНЬ“НЫҢ РЕСПУБЛИКА КОНТОРАСЫ

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
3 нче январьда
ЧИО-ЧИО-САН

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген һәм 31 нче декабрьдә
БӘХЕТСЕЗ ЕГЕТ

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

ГАЗ АА АВТОМАШИНАСЫ САТЫЛА

Зур Драма Театры
Бүген һәм 31 нче декабрьдә
АНДЖЕЛО

БҮГЕН КИНОЛАРДА:
„ЭЛЕКТРО“ — Кино-новелла ЮЛЛАРДА
„ЮНИОН“
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ — СТЕПАН РАЗИН
„ПИОНЕР“
„ГОЛОСВИНЕ“ — КАЙТУ
„ЧАТКЫ“ — ЮЛЛАРДА ТОРМЫШНЫҢ БӘЯСЕ
„РОТ-ФРОНТ“
„КУЛЬТУРА САРАЕ“ — ВАТАН КЫЗЫ

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: пропаганда бүлеге һәм экономик бүлек 18—22, секретариат 5—86, партия бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, төнге редакция 3—75, типография 35—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19

ПФ 3891 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ. 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 5588.